КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1265

2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыру буенча төбәкара һәм төбәк программаларын эшләү һәм тормышка ашыру тәртибе турында» 2016 елның 10 сентябрендәге 903 номерлы карары нигезендә һәм газ белән тәэмин итү һәм газ бүлү системасының ышанычлылыгын арттыру, Татарстан Республикасы кулланучыларын табигый газ белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин